УРТА КУМОР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

**2019 елның 26 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 26 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Үзәк, Май, Яр буе урамнарының юл полотносын торгызу (вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Урта Комар авылы юлларын кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- артезиан скважиналарын куллануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатор тикшеренүләрне әзерләү чараларын тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 171 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 101.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 101 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Урта Комар авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.
Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Урта Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2020 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Үзәк, Майская, Яр буе урамнарының юл полотносын торгызу (вак таш җәю), проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Урта Комар авылы юлларын кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- артезиан скважиналарын куллануга лицензия алу өчен документлар пакетын һәм лаборатор тикшеренүләрне әзерләү чараларын тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»
- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы: Ю.И.Исынбаев